| Республика Татарстан<br>СОВЕТ АЛЕКСАНДРОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | Татарстан Республикасы<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>АЛЕКСАНДРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 05 »ноябрь 2020 ел с.Александровка № 4

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Татар Карамалысы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге башлыгы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1.2020 елның 18 ноябрендә Александровка авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 14 сәгатькә билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: «I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан, Александровка авыл җирлегендә теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 250 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1) Татар Карамалы т. п. коры агачлар һәм куаклар кисү;

2) Татар Карамалы т.п. урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (яктырткычлар сатып алу, урнаштыру)

3) Татарские Карамалы т. п. өчен урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр сатып алу;

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Александровка авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрүне йөкләргә.

4.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http:// sarmanovo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Сарман муниципаль районы сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге башлыгы А.Р.Гафиятуллин